СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 24 » март 2017 ел** **№ 115**

**«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр кертү турында**

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнарга туры китерү максатларында Арча район Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы «муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында» Арча район Советының17.02.2011 ел, №35-1 карары белән расланган "Арча муниципаль районы" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 18 пунктта «Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алынган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр» түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә, аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И. Г. Нуриев